КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 22 май

г.Казань

№ б-1125

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 апрель, б-759 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 ноябрь, б-2471 нче; 2021 ел, 30 август, б-1688 нче; 2022 ел, 24 гыйнвар, б-96 нчы; 2022 ел, 5 декабрь, б-2716 нчы; 2023 ел, 18 гыйнвар, б-58 нче; 2023 ел, 28 август, б-1931 нче; 2024 ел, 30 гыйнвар, б-163 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү проектларын тормышка ашыру буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан Б.Н.Әхмәтҗановны, Р.Х.Әхмәтҗановны, Д.А.Кремлевны, Р.Ф.Камаловны, Р.А.Мусаевны, Г.Р.Нигъмәтуллинаны һәм Л.З. Фатыйховны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Илдар Фоат улы Бәдриевны;

«Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы технологияләрне үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешмасының Татарстан Республикасы белән эшләү бүлеге башлыгы Марсель Йосыф улы Гыйльмиевны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Рөстәм Зөфәр улы Зәмдихановны (килешү буенча);

«Мобильные ТелеСистемы» гавами акционерлык җәмгыятенең корпоратив клиентлар белән эшләү департаменты директоры Денис Рафаэль улы Зимагуловны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Светлана Витальевна Карлинаны (килешү буенча);

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе башлыгы Илшат Илсур улы Сәлимҗановны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгының беренче урынбасары Илфарт Фәтхрислам улы Сафиуллинны;

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Аяз Әнис улы Ямалетдиновны (килешү буенча);

«СКБ Контур» җитештерү фирмасы» акционерлык җәмгыяте, дәүләт органнары һәм контрольдә тотучы органнар белән эшләү буенча кече төбәк үзәге директоры урынбасары Булат Рафис улы Шакиров (килешү буенча);

Сәрия Харис кызы Сабурскаяның вазыйфа атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, «Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы рәисе».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин